**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Регламент Аппарата Президента Республики Татарстан

В связи с созданием государственной информационной системы Республики Татарстан «Система планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан» **постановляю**:

1. Внести в Регламент Аппарата Президента Республики Татарстан, утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 4 апреля 2008 года № УП-162 «Об утверждении Регламента Аппарата Президента Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 12 июля 2010 года № УП-445, от 7 октября 2010 года № УП-667, от 7 мая 2013 года № УП-385, от 23 ноября 2013 года № УП-1144, от 14 августа 2014 года № УП-788, от 22 мая 2015 года № УП-473 и от 30 января 2016 года № УП-67), изменения согласно приложению.

2. Руководителю Аппарата Президента Республики Татарстан обеспечить ознакомление работников Аппарата Президента Республики Татарстан с изменениями, внесенными настоящим Указом в Регламент Аппарата Президента Республики Татарстан.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
25 июня 2016 года
№ УП-550

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «25» июня 2016 года

№ УП-550

**Изменения,**
**вносимые в Регламент Аппарата Президента Республики Татарстан, утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 4 апреля 2008 года № УП-162 «Об утверждении Регламента Аппарата Президента Республики Татарстан»**

1. Пункт 2.4 изложить в следующей редакции:

«2.4. Предложения в проект плана работы Аппарата на предстоящий квартал вносятся в Систему планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан по установленной форме не позднее 15 числа месяца, предшествующего первому месяцу планируемого квартала.».

2. В пункте 2.5:

а) абзац первый изложить в следующей редакции:

«2.5. Управление по работе с территориями Президента Республики Татарстан (далее – Управление по работе с территориями) обобщает предложения в проект плана работы Аппарата и представляет окончательный проект плана работы Аппарата после согласования с Секретарем Совета Безопасности Республики Татарстан, помощниками Президента Республики Татарстан и руководителями структурных подразделений Аппарата не позднее 25 числа месяца, предшествующего первому месяцу планируемого квартала, для рассмотрения и утверждения Руководителю Аппарата Президента Республики Татарстан (далее также – Руководитель Аппарата).»;

б) дополнить абзацем следующего содержания:

«Обобщение предложений в проект плана работы Аппарата, его согласование и утверждение плана работы Аппарата осуществляется посредством Системы планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан.».

3. Пункты 2.6 - 2.10 изложить в следующей редакции:

«2.6. Доступ структурных подразделений (должностных лиц) Аппарата к утвержденному Руководителем Аппарата плану работы Аппарата предоставляется посредством Системы планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан.

План работы Аппарата является обязательным для исполнения структурными подразделениями (должностными лицами) Аппарата в

соответствии с их компетенцией. Ответственность за реализацию мероприятий, предусмотренных планом работы Аппарата, возлагается на руководителей соответствующих структурных подразделений Аппарата.

2.7. В целях координации деятельности органов государственной власти Республики Татарстан и их взаимодействия с органами местного самоуправления, на основе предложений государственных органов Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления в Республике Татарстан формируется месячный бюллетень основных мероприятий, проводимых на территории Республики Татарстан (далее – месячный бюллетень). Предложения вносятся в Систему планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан не позднее 25 числа месяца, предшествующего планируемому месяцу. Управление по работе с территориями формирует месячный бюллетень и представляет его для рассмотрения и утверждения Руководителю Аппарата не позднее 27 числа месяца, предшествующего планируемому месяцу.

Формирование и утверждение месячного бюллетеня осуществляется посредством Системы планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан.

2.8. На основе предложений Секретаря Совета Безопасности Республики Татарстан, помощников Президента Республики Татарстан, структурных подразделений Аппарата, а также Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан, Аппарата Государственного Совета Республики Татарстан, иных государственных органов Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления, общественных организаций формируется недельный бюллетень основных мероприятий, проводимых на территории Республики Татарстан (далее – недельный бюллетень). Предложения вносятся в Систему планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан каждую пятницу. Управление по работе с территориями формирует недельный бюллетень и представляет его для рассмотрения и утверждения Руководителю Аппарата не позднее субботы, предшествующей планируемой неделе.

Формирование и утверждение недельного бюллетеня осуществляется посредством Системы планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан.

2.9. Доступ структурных подразделений (должностных лиц) Аппарата, государственных органов Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, органов местного самоуправления в Республике Татарстан к утвержденному Руководителем Аппарата месячному бюллетеню предоставляется посредством Системы планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан не позднее 29 числа месяца, предшествующего планируемому месяцу. Месячный бюллетень также направляется в Администрацию Президента Российской Федерации, аппараты Совета Федерации и Государственной Думы

Федерального Собрания Российской Федерации, аппарат полномочного представителя Президента Российской Федерации в Приволжском федеральном округе не позднее 29 числа месяца, предшествующего планируемому месяцу.

2.10. Доступ структурных подразделений (должностных лиц) Аппарата к утвержденному Руководителем Аппарата недельному бюллетеню предоставляется посредством Системы планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан не позднее субботы, предшествующей планируемой неделе.».

4. Абзац первый пункта 3.6 изложить в следующей редакции:

«3.6. Оповещение участников о месте, времени и повестке совещания с направлением информационных материалов осуществляется не позднее чем за два дня до даты проведения совещания, в том числе с использованием Системы планирования и контроля мероприятий в Республике Татарстан.».

---

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын булдыру белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентын раслау турында» 2008 елның 4 апрелендәге ПУ-162 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 7 октябрендәге ПУ-667 номерлы, 2013 елның 7 маендагы ПУ-385 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1144 номерлы, 2014 елның 14 августындагы ПУ-788 номерлы, 2015 елның 22 маендагы ПУ-473 номерлы һәм 2016 елның 30 гыйнварындагы ПУ-67 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына әлеге Указ нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләрен таныштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 25 июнь
№ ПУ-550

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның «25» июнендәге
ПУ-550 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентын раслау турында» 2008 елның 4 апрелендәге ПУ-162 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

1. 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Киләсе кварталга Аппаратның эш планы проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасына билгеләнгән формада планлаштырыла торган кварталның беренче ае алдыннан килүче айның 15 нче числосыннан да соңга калмыйча кертелә.».

2. 2.5 пунктта:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе (алга таба – Территорияләр белән эшләү идарәсе) Аппаратның эш планы проектына тәкъдимнәрне гомумиләштерә һәм Аппарат эш планының соңгы проектын Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчеләре һәм Аппаратның структур бүлекчәләре җитәкчеләре белән килештергәннән соң, планлаштырыла торган кварталның беренче ае алдыннан килүче айның 25 нче числосыннан да соңга калмыйча, карап тикшерү һәм раслау өчен Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә (алга таба шулай ук – Аппарат Җитәкчесе) кертә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Аппаратның эш планы проектына тәкъдимнәрне гомумиләштерү, аны килештерү һәм Аппаратның эш планын раслау Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы аша башкарыла.».

3. 2.6 - 2.10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Аппаратның структур бүлекчәләре (вазыйфаи затлары) Аппарат Җитәкчесе тарафыннан расланган Аппаратның эш планыннан Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы аша файдалана ала.

Аппаратның структур бүлекчәләренә (вазыйфаи затларына) үз компетенцияләре чикләрендә Аппаратның эш планы үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

Аппаратның эш планында каралган чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплылык Аппаратның тиешле структур бүлекчәләре җитәкчеләренә йөкләнә.

2.7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген һәм аларның җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлеген координацияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә уздырыла торган төп чараларның айлык бюллетене (алга таба – айлык бюллетень) формалаштырыла. Тәкъдимнәр Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасына планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның 25 нче числосыннан да соңга калмыйча кертелә. Территорияләр белән эшләү идарәсе айлык бюллетеньне формалаштыра һәм аны планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның 27 нче числосыннан да соңга калмыйча, карап тикшерү һәм раслау өчен Аппарат Җитәкчесенә кертә.

Айлык бюллетеньне формалаштыру һәм раслау Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы аша башкарыла.

2.8. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчеләре, Аппарат, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структур бүлекчәләре, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар тәкъдимнәре нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә уздырыла торган төп чараларның атналык бюллетене (алга таба – атналык бюллетень) формалаштырыла. Тәкъдимнәр Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасына һәр җомга саен кертелә. Территорияләр белән эшләү идарәсе атналык бюллетеньне формалаштыра һәм аны планлаштырыла торган атна алдыннан килүче атнаның шимбә көненнән дә соңга калмыйча, карап тикшерү һәм раслау өчен Аппарат Җитәкчесенә кертә.

Атналык бюллетеньне формалаштыру һәм раслау Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы аша башкарыла.

2.9. Аппаратның структур бүлекчәләре (вазыйфаи затлары), Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары Аппарат Җитәкчесе тарафыннан расланган айлык бюллетеньнән Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм

контроль системасы аша планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның 29 нчы числосыннан да соңга калмыйча файдалана ала. Айлык бюллетень шулай ук Россия Федерациясе Президенты Администрациясенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы һәм Дәүләт Думасы аппаратларына, Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле аппаратына планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның 29 нчы числосыннан да соңга калмыйча җибәрелә.

2.10. Аппаратның структур бүлекчәләре (вазыйфаи затлары) Аппарат Җитәкчесе тарафыннан расланган атналык бюллетеньнән Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы аша планлаштырыла торган атна алдыннан килүче атнаның шимбә көненнән дә соңга калмыйча файдалана ала.».

4. 3.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Киңәшмәдә катнашучыларга мәгълүмати материаллар белән бергә аны уздыру урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында киңәшмә уздыру датасына ике көн кала, шул исәптән Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасын файдаланып, хәбәр ителә.».

---